ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 61-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 61-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 18 апреле
№ 266-VII ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1-2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 34 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), 34 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлектәге 96 пунктны өстәргә:

«96) Татарстан Республикасы милкендә булган спорт объектларын төзүне, реконструкцияләүне һәм аларга ремонт ясауны оештыру, башка спорт корылмаларын булдыру һәм аларны карап тоту;»;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлектәге 7 пунктны өстәргә:

«7) федераль милектә, муниципаль милектә, шулай ук юридик затлар милкендә, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, яки физик затлар милкендә булган спорт объектларын төзүне, аларны реконструкцияләүне һәм аларга ремонт ясауны оештыруда, башка спорт корылмаларын булдыруда һәм аларны карап тотуда катнашырга.»;

в) 4 өлешкә «һәм башка спорт корылмаларыннан» сүзләрен өстәргә;

2) 11 статьяның 4 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) спорт объектларын төзү, реконструкцияләү һәм аларга ремонт ясау, башка спорт корылмаларын булдыру һәм аларны карап тоту;»;

3) 12 статьяда:

а) 1 өлештә «спорт объектларыннан файдаланучылар» сүзләрен «спорт объектларыннан һәм башка спорт корылмаларыннан файдаланучылар» сүзләренә алмаштырырга, «спорт объектларыннан файдаланучыларның» сүзләрен «спорт объектларыннан һәм башка спорт корылмаларыннан файдаланучыларның» сүзләренә алмаштырырга;

б) $1^2$ өлештә «спорт объектларыннан» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмаларыннан» сүзләрен өстәргә;

4) 20 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында «спорт объектларын,» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмаларын,» сүзләрен өстәргә;

5) 27 статьяда:

а) исемдә «һәм башка спорт корылмалары» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә «Спорт объектлары» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмалары» сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Халыкның спорт объектлары белән тәэмин ителүгә ихтыяҗы шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә билгеләнә.»;

г) 4 өлештә «шәһәр төзелеше регламентлары» сүзләрен «шәһәр төзелешен зоналаштыру документлары» сүзләренә алмаштырырга;

д) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Спорт объектларын архитектур-төзелеш проектлау, төзү һәм реконструкцияләү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә, шул исәптән инвалидларның спорт объектларына тоткарлыксыз керүен тәэмин итү турындагы таләпләрне үтәп башкарыла.»;

е) 6 өлештә «спорт объектлары» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмалары», «спорт объектларында» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмаларында» сүзләрен өстәргә;

ж) $6^1$ өлештә «спорт объектларыннан» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмаларыннан» сүзләрен өстәргә;

з) түбәндәге эчтәлектәге $8^1$ өлешне өстәргә:

«$8^1$. Күчемсез мөлкәт объекты булмаган спорт корылмасыннан төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара физкультура чараларының һәм спорт чараларының бердәм календарь планына, Татарстан Республикасының рәсми физкультура чараларының һәм спорт чараларының календарь планнарына кертелгән физкультура чарасын яисә спорт чарасын уздыру өчен файдалану Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең физик культура һәм спорт өлкәсендәге органы карары белән Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

и) 10 өлештә «спорт объектлары» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмалары» сүзләрен өстәргә;

6) 28 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) физик культура һәм спорт өлкәсендә республика программаларын һәм проектларын, муниципальара программаларны һәм проектларны оештыру һәм

гамәлгә ашыру, шул исәптән Татарстан Республикасы милкендә булган спорт объектларын төзүне, реконструкцияләүне һәм аларга ремонт ясауны, башка спорт корылмаларын булдыруны һәм аларны карап тотуны оештыру;».

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Физик культура һәм спорт турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 8 августындагы 326-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә һәм «Этил спирты, алкоголь продукциясе һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законның 16 статьясына бәйле рәвештә эшләнде.

Күрсәтелгән үзгәрешләр белән Россия Федерациясе субъектларының физик культура һәм спорт өлкәсендәге вәкаләтләренә Россия Федерациясе субъектлары милкендә булган спорт объектларын төзүне, аларны реконструкцияләүне һәм аларга ремонт ясауны оештыру, башка спорт корылмаларын булдыру һәм аларны карап тоту вәкаләтләре дә өстәлә.

Шулай ук Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына федераль милектә, муниципаль милектә, шулай ук юридик затлар милкендә, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, яки физик затлар милкендә булган спорт объектларын төзүне, аларны реконструкцияләүне һәм аларга ремонт ясауны оештыруда, башка спорт корылмаларын булдыруда һәм аларны карап тотуда катнашу хокукы бирелде.

Закон проекты «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына корреспондент үзгәрешләр кертүне күздә тота.

**«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Физик культура һәм спорт турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү белән Татарстан Республикасына Татарстан Республикасы милкендә булган спорт объектларын төзүне, реконструкцияләүне һәм аларга ремонт ясауны оештыру, башка спорт корылмаларын булдыру һәм аларны карап тоту вәкаләте биреләчәк.

Шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына федераль милектә, муниципаль милектә, шулай ук юридик затлар милкендә, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, яки физик затлар милкендә булган спорт объектларын төзүне, аларны реконструкцияләүне һәм аларга ремонт ясауны оештыруда, башка спорт корылмаларын булдыруда һәм аларны карап тотуда катнашу хокукы бирелде.

Бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә шуны билгеләп үтәбез, күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, тиешле чыгым йөкләмәләре кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы бюджетының хәзерге вакытта күләмен бәяләү мөмкин булмаган өстәмә чыгымнары барлыкка килүгә китерәчәк.